**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет Учаллинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Үчәлле авылы җирлеге башкарма комитеты**

ул. Советская, д. 51, село Учалле, Азнакаевского муниципального района, 423317

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы Азнакай муниципаль районы 423317

Тел./факс(885592)36-8-32; E-mail:Uchal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 июнь 2018 ел №8

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең 05.04.2018 № 3 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен закупкалар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар әзерләү һәм кабул итү тәртибенә таләпләрне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата таләпләргә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар өлкәсендә, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы, «Заказ бирүчеләрнең сатып алына торган аерым төр товарларга, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә (шул исәптән товарларның, эшләренең, хезмәт күрсәтүләренең иң чик бәяләренә) таләпләрне билгеләү буенча гомуми кагыйдәләрне раслау турында» 2015 елның 2 сентябрендәге карарлары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең 05.04.2018 № 3 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен закупкалар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар әзерләү һәм кабул итү тәртибенә таләпләрне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле

авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата таләпләргә үзгәреш кертергә, 17 пунктындагы «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«б) җирлек башкарма комитетының үзе, казна учреждениеләре, бюджет учреждениеләре һәм унитар предприятиеләр тарафыннан сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләрен) сайлап алу тәртибе (алга таба - ведомство исемлеге);».

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http//aznakayevo. tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина